# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

**1 статья.** «Җәмәгать тәртибен һәм идарә итү тәртибен бозган өчен административ җаваплылык турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. 1 статьяны төшереп калдырырга.

2. 2 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләүнең икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының егерме процентын тотып калып, бер айдан ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә, ә аңа карата ачылган эшнең шартлары буенча, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, әлеге чараларны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, ул унбиш тәүлеккә кадәр административ кулга алына.».

3. 4 статьяда:

беренче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең өчтән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

икенче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләүнең икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

өченче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләүнең өчтән бердән алып бер минималь күләменә кадәр штраф салына яисә, хезмәт хакының егерме процентын тотып калып, бер айдан алып ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә, ә аңа карата

Исп.,тел.64-
sak-sam

323

ачылган эшнең шартлары буенча, тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, әлеге чараларны куллану җитәрлек түгел дип табылган аерым очракларда, ул унбиш тәүлеккә кадәр административ кулга алына.»;

дүртенче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ата-аналарга яисә аларны алыштыручы затларга хезмәт өчен түләүнең икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

4. 5 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләүнең өчтән бердән алып бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

5. 6 статьяның икенче абзацында «, ә аңа карата ачылган эшнең шартлары буенча тәртип бозучының шәхесен исәпкә алып, әлеге чараны куллану җитәрлек түгел дип табылган очракта, ул унбиш тәүлеккә кадәр административ кулга алына» сүзләрен төшереп калдырырга.

6. 7 статьяда:

беренче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яки ата-аналарына яисә аларны алыштыручы затларга хезмәт өчен түләүнең өчтән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

икенче өлешне төшереп калдырырга;

өченче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ата-аналарына яисә аларны алыштыручы затларга хезмәт өчен түләүнең өчтән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

7. 8 статьяны төшереп калдырырга.

8. 9 статьяда:

беренче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең өчтән бердән алып бер минималь күләменә кадәр штраф салына.»;

икенче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт өчен түләүнең икедән бердән алып ике минималь күләменә кадәр штраф салына.».

9. 11 статьяны төшереп калдырырга.

10. 12 статьяда:

беренче өлешнең икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кисәтү ясала яисә хезмәт өчен түләүнең биш минималь күләменә кадәр штраф салына яки, хезмәт хакының 20 процентына кадәрен тотып калып, ике айга кадәр төзәтү эшләренә җәлеп ителә.»;

икенче өлешне төшереп калдырырга.

324

11. 13 статьяның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«хезмәт өчен түләүнең икедән бер минималь күләменә кадәр штраф салына.».

12. 14 статьяны төшереп калдырырга.

13. 15 статьяда «II статья буенча һәм хокук саклау органнарының башка вәкаләтле затлары» сүзләрен төшереп калдырырга.

14. 17 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Әлеге законның 2 статьясында, 4 статьясының өченче һәм дүртенче өлешләрендә, 5, 6, 7, 9, 10, 12, 13 статьяларында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр район (шәһәр) суды тарафыннан карала.».

15. 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«20 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозулар турындагы эшләр административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда карала.».

16. 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«21 статья. Әлеге Законда каралган административ хокук бозуны кылган затларны административ тоткарлау, шәхси карап тикшерү һәм әйберләрен карап тикшерү административ хокук бозулар турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.».

17. 22, 23 статьяларны төшереп калдырырга.

**2 статья.** Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

М.Шәймиев

Казан шәһәре,
2001 елның 27 июне
№ 895